**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуганы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татар Шуганы авылы № 56 «18 » апрель 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлегенең 2020 елның 27 февралендәге 167 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (24.04.2020 №173, 15.06.2020 №176, 16.12.2020 №14, 28.10.2021 №38, 08.04.2022 №52 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль закон нигезендә,

**Татар Шуганы авыл җирлеге карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлегенең 2020 елның 27 февралендәге 167 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (24.04.2020 №173, 15.06.2020 №176, 16.12.2020 №14, 28.10.2021 №38, 08.04.2022 №52 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унберенче абзац өстәргә:

«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

б) унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга.

1.2. 20 статьяның 2нче пунктында «җирле бюджет кытлыгы,» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган өлеше күләменнән тыш,» сүзләрен өстәргә.

1.3. 55 статьяның унбишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

1.4. 58 статьяның 3 пунктында «әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советының 2022 елның 08 апрелендәге 52 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлегенең 2020 елның 27 февралендәге 167 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (24.04.2020 №173, 15.06.2020 №176, 16.12.2020 №14, 28.10.2021 №38 карарлар редакциясендә)» карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай районы авыл җирлегенең бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Хәертдинов М.Ш.